Тарих онытмый // Көмеш кыңгырау. – 2025. – №25 (28 июнь). – Б. 2.



# Тарих онытмый

**Яр Чаллы шәһәре 14нче китапханә хезмәткәрләре «Хәтер һәм кайгы көне» үткәрделәр. Анда мәктәп яны лагерена йөрүче укучылар катнашты.**

Балаларны Антуан де Сент-Экзюпери әсәренең төп герое Кечкенә принц каршы алды. Ул аларны экран аша сәламләде.

Француз язучысы, очучы Сент-Экзюпери үзенең китабы аша күп нәрсәгә өйрәтә. Аның «Мин балачак иленнән» дигән сүзләре бик ошады.

«Сугыш балачакны юк итте: яндырды, атты, үтерде, бомба белән дә, пуля белән дә, ачлык белән», - дип яза ул. Сент-Экзюпери 1944 елда фашистлар белән һава сугышында батырларча һәлак була.

Китапханәчеләр батыр малайлар һәм кызлар турында сөйләделәр: алар элемтәче, радист булганнар, разведкага да йөргәннәр. Батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр. Бик кубесе һәлак булган. Зина Портнова, Марат Казей, Лёня Голиков... Тарих онытмый, барысы да хәтердә.

Балалар Ленинград блокадасы, Мәскәү, Сталинград өчен сугыш чоры турында да белделәр. Сугыш турындагы шигырь, жыр, хикәяләр балаларга кеше гомере, Ватан, батырлык турында аңларга ярдәм итте. Чара ахырында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарны бер минут тынлык белән искә алдылар.